КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 март г.Казань № 282

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче кайбер категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 июнь, 251 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 5 сентябрь, 432 нче; 2007 ел, 5 февраль, 35 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2010 ел, 29 ноябрь, 961 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 13 февраль, 83 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2020 ел, 23 ноябрь, 1053 нче; 2021 ел, 3 февраль, 47 нче; 2021 ел, 20 февраль, 92 нче, 2021 ел, 10 май, 322 нче, 2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче, 2022 ел, 3 март, 194 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнарның авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче кайбер категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибенә, 5 пунктның сигезенче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекләре» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекләре» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 20 февраль, 103 нче; 2015 ел, 10 декабрь, 932 нче; 2017 ел, 14 ноябрь, 873 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1133 нче; 2020 ел, 30 июль, 636 нчы; 2020 ел, 20 ноябрь, 1035 нче; 2021 ел, 26 апрель, 286 нчы, 2021 ел, 20 июль, 606 нчы, 2022 ел, 28 гынвар, 66 нчы, 2022 ел, 21 апрель, 382 нче, 2022 ел, 6 июнь, 524 нче,

2022 ел, 7 октябрь, 1082 нче  карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә, 2.4 пунктның өченче абзацында «Пенсия фонды» сүзләрен «Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин